КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1131

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибен һәм Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибен һәм Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 17 июль, 500 нче; 2018 ел, 14 август, 666 нчы; 2021 ел, 2 март, 109 нчы; 2021 ел, 14 июль, 569 нчы; 2023 ел, 6 март, 210 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органының үзәк аппараты

структурасы стандартын исәпкә алып, республика башкарма хакимият органының штат расписаниесен раслау максатларында республика башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре санын бәяләү методикасын куллану рөхсәт ителә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәт күрсәтүләргә) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибендә:

1.3 пунктта татар текстында «дәүләт учреждениеләренең» сүзләрен «чиратдагы елга һәм план чорына дәүләт учреждениеләренең» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

Дәүләт учреждениеләренең элемтә хезмәтләре белән тәэмин ителеше нормативлары

| Элемтә хезмәтләре исеме | Үлчәү берәмлеге | Тәэмин ителеш нормасы |
|---|---|---|
| Телефон аша җирле (зона эчендәге) тоташтырулар | аена һәр хезмәткәргә минут | 220 |
| Телефон аша шәһәрара тоташтырулар | аена һәр хезмәткәргә минут | 4 |
| Тавыш белән мәгълүмат тапшыру өчен абонент түләве булган абонент номерлары | дәүләт учреждениесенең штат саны 10 берәмлеккә кадәр (10 берәмлекне кертеп) булганда дәүләт учреждениесенә номерлар | 1 |
| | дәүләт учреждениесенең штат саны 11 берәмлек һәм аннан күбрәк булганда һәр хезмәткәргә номерлар | 0,1 |
| «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре | елга түләүләр | 12»; |

2 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

Канцелярия товарлары һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин ителеш нормасы

| Товар исеме | Үлчәү берәмлеге | Саны | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Канцелярия товарлары | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Офис кәгазе 80 г/кв.метр, А4, 500 бит | пачка | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Кара графит карандаш | данә | 3 | бер хезмәткәргә елына |
| Бетергеч | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Шариклы ручка | данә | 3 | бер хезмәткәргә елына |
| Шариклы ручка өчен стержень | данә | 3 | бер хезмәткәргә елына |
| Текст маркерлары җыелмасы, 4 төс | данә | 0,5 | бер хезмәткәргә елына |
| Линейка, 30 сантиметр | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Карандаш җилем | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| 80 – 96 битле дәфтәр яки блокнот | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Кайчы | данә | 0,5 | бер хезмәткәргә елына |
| Штрих-корректор | данә | 0,5 | бер хезмәткәргә елына |
| Көндәлек, А5 | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Җилемле тасма (скотч) | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Кечкенә кәгазь кыстыргыч, кап 100 данә | данә | 2 | бер хезмәткәргә елына |
| Кыска язмалар өчен блок 90 × 90 миллиметр, 1 000 бит | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Тизберкеткечсез картон папка, бауда, А4 | данә | 5 | бер хезмәткәргә елына |
| Тизберкеткечле картон папка, бауда, А4 | данә | 5 | бер хезмәткәргә елына |
| Папка-почмак, комплект 20 данә, А4 | данә | 1 | бер хезмәткәргә елына |
| Кәгазьләр өчен степлер № 10 | данә | 0,5 | бер хезмәткәргә елына |
| Степлер өчен скобалар №10, төргәктә 1 000 данә | данә | 0,5 | бер хезмәткәргә елына |
| Хуҗалык-көнкүреш товарлары | | | |
| Сыек бәдрәф сабыны, 5 литрлы бутыль | шешә | 0,2 | бер хезмәткәргә елына |
| Бәдрәф кәгазе, 200 метрлы рулон | рулон | 3 | бер хезмәткәргә елына |
| Чистарту порошогы, 400 грамм | данә | 6 | елына бер урынга (бәдрәфкә) |
| Сантехниканы чистарту чарасы, 500 миллилитр | данә | 6 | елына бер урынга (бәдрәфкә)»; |

әлеге карар белән расланган Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасында:

2.2 пунктта «министрлык, ведомство» сүзләрен – «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма

органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт учреждениесенең штат саны кимендә 6 берәмлек булганда:

дәүләт учреждениесе җитәкчесе урынбасары вазыйфасын гамәлгә кертү рөхсәт ителми;

структур бүлекчәләр формалаштырылмаска мөмкин.

Дәүләт учреждениесенең штат расписаниесендә «төп белгеч» категориясе вазыйфалары саны штат санынан – кимендә 20 процент, «1 категорияле белгеч», «2 категорияле белгеч», «белгеч» категорияләре кимендә 5 процент тәшкил итәргә тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин